КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 июнь г.Казань № 528

«Созвездие - Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән «Созвездие - Йолдызлык» ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестивале һәм эшләүче яшьләрнең «Наше время – Безнең заман» еллык ачык республика телевизион иҗат фестивале чараларын үткәрүгә бәйле коммерциячел булмаган оешмалар чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 9 пунктындагы өченче абзацыннан, 10 пунктындагы алтынчы абзацыннан, 28 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин